РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
ГЛАВА
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«УРМАНАЕВСКОЕ СЕЛЬСКОЕ
ПОСЕЛЕНИЕ» АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
АЗНАКАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
«УРМАНАЙ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШЛЫГЫ

ул. Татарстан д.15«а», с.Урманаево,
Азнакаевский район, 423311

Татарстан урамы, йорт 15 “а”, Урманай авылы
Азнакай районы, 423311

Тел./факс(8-85592)4-30-49/4-31-56; E-mail Azn.Urman@tatar.ru; http://aznakayevo.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«11» ноябрь 2019 ел № 31

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел № 131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел № 45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге Уставы белән, карар чыгарам**:**

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында Урманай авылы Татарстан урамы буенча 1-34 нче йортларда теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын 2019 елның 23 ноябрендә 10 сәгать 00 минутка билгеләргә.
2. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында, Г. Галиев урамы буенча 1-57 йортларда теркәлгән сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын 2019 елның 23 ноябрендә 11 сәгать 00 минутка билгеләргә.
3. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында Татарстан урамы буенча 35- 63 йортларда теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын 2019 елның 23 ноябрендә 12 сәгать 00 минутка билгеләргә.

4. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Беренче Май бистәсе торак пунктында Г. Галиев урамы буенча 58-115 йортларда теркәлгән, сайлау хокукына ия гражданнар өчен үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының дүртенче этабын 2019 елның 23 ноябрендә 13 сәгать 00 минутка билгеләргә.

5. Билгеләргә:

- Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлегенең Урманай торак пунктында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча халык җыенын оештыручы – Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитеты;

- гражданнар җыенының беренче этаптабын уздыру вакыты-2019 елның 23 ноябрендә 10.00 сәгатьтән 11.00 сәгатькә кадәр;

- беренче этапны үткәрү урыны-Урманай авылы, Татарстан урамы, 11, МКД йортлары;

- гражданнар җыенының икенче этаптабын уздыру вакыты-2019 елның 23 ноябрендә 11.00 сәгатьтән 12.00 сәгатькә кадәр;

- икенче этапны үткәрү урыны-Урманай авылы, Г. Галиев урамы, 32А йорт, мәктәп янында;

- гражданнар җыенының өченче этаптабын уздыру вакыты-2019 елның 23 ноябрендә 12.00 сәгатьтән 13.00 сәгатькә кадәр;

- өченче этапны үткәрү урыны-Урманай авылы, Татарстан урамы, 45 нче йорт, янында;

- гражданнар җыенының өченче этаптабын уздыру вакыты-2019 елның 23 ноябре, 13.00 сәгатьтән 14.00 сәгатькә кадәр;

- дүртенче этапны үткәрү урыны-Урманай авылы, Г. Галиев урамы, 82нче йорт, янында;

6. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитетына тәкъдим итәргә:

- 2019 елның 13 ноябреннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Урманай авыл җирлеге башкарма комитетында гражданнар җыены карарына чыгарыла торган материаллар белән танышу хокукын гражданнарга түбәндәге адрес буенча бирергә:
Урманай авылы, Татарстан ур., 15а;

- сайлау хокукына ия булган Урманай торак пунктында яшәүчеләр исемлеген төзергә;

- гражданнар җыенына мәгълүмати материаллар әзерләргә;

- Урманай торак пункты халкына массакүләм мәгълүмат чараларында һәм гражданнар җыены турында башка ысуллар белән хәбәр итәргә.

7. Гражданнар җыенына чыгарыла торган сорауны расларга:

«Сез, 2020 елда Урманай авыл җирлеге Урманай торак пункты территориясендә 1 Төркем инвалидлардан, Бөек Ватан сугышы ветераннарыннан һәм катнашучылардан, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннарыннан, көндезге уку формасында укучы студентлардан тыш, яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 300 сум күләмендә үзара салым кертү һәм бу акчаларның җирле әһәмияткә ия булган түбәндәге сорауларны хәл итүгә юнәлтү белән килешәсезме:

- Урманай авылында юлларны кардан чистарту,

- Урманай авылы Г. Галиев һәм Татарстан урамнарында асфальт-бетон өслекле юллардагы чокырларны ямау(килешү буенча сатып алу, урнаштыру, эшләр өчен түләү);

« РИЗА» «КАРШЫ»

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru, Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә түбәндәге адрес буенча: http://aznakaevo.tatarstan.ru. һәм түбәндәге адреслар буенча урнашкан мәгълүмат стендларында урнаштырырга:

-423311,ТР, Азнакай районы, Урманай авылы, Татарстан ур., 15А й. (Башкарма комитет администрациясе бинасы);

-423311,ТР, Азнакай районы, Урманай авылы, Татарстан ур., 27а й. (Урманай авылы мәдәният йорты).

9. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

10. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз артымнан калдырам.

Башлык: А.И.Закиров